РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АКСУНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

22 сентябрь 2022 № 58-3

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең халык дружинасы турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында», 2022 елның 28 июнендәге 219-ФЗ номерлы «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юдыруга) каршы тору һәм терроризмны финанслау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законнар нигезендә Аксу авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге халык дружинасы турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1-53 номерлы Татарстан Республикасы Аксу авыл җирлеге Советы карарына (2020 елның 21 маендагы 88-5 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6.3 пунктының 5 абзацын киләсе редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«-"Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юдыруга) каршы тору һәм террорчылыкны финанслау турында" 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экстремистлык эшчәнлегенә яисә терроризмга катнашы турында мәгълүматлары булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Аксу авыл
җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов